| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

«22» апрель, 2019 г. с.Б.Кайбицы № 160

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә җирләрне куллану муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәне раслау турында

РФ Җир кодексының 72 статьясы, 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы «Дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр хокукларын саклау турында»гы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә җирләрне куллану муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне яңа редакциядә расларга, һәм аны кушымтадагы кебек бәян итәргә.
2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2010 елның 12 ноябрендәге 11номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә җирләрне куллану муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында» карарын гамәлдән чыккан дип санарга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җир һәм милек мөнәсәбәтләре Палатасы» МКУ Рәисе О.Д. Макаровага йөкләргә.

Совет Рәисе, Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин